**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2024елның 7 марты** **20-РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 16 февралендәге 6-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 31 маендагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 320-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 05 декабрендәге 512-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон белән, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 июлендәге 370-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Лаеш муниципаль районы Советы **карар чыгарды**:

2. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 16 февралендәге 6-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына (алга таба муниципаль район башлыгының 2018 елның 16 февралендәге 6-РС номерлы карары) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 2.1 пунктының 4 абзацында "(алга таба - офшор компанияләре)" сүзләрен төшереп калдырырга, "Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә үз файдаларын алучылар, бенефициар хуҗалары һәм контрольдә тотучылар турында мәгълүматны ачмыучылар һәм бирмәүчеләр"" сүзләрен өстәргә.;

- 5 нче абзац үз көчен югалткан дип тану;

- 6 нчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- "Контроль итүче зат" төшенчәсе "Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында" 2008 елның 29 апрелендәге 57-ФЗ номерлы Федераль законның 5

статьясында да кулланыла. «Файда алучы"» һәм «бенефициар хуҗа» төшенчәләре «Җинаять юлы белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (юуга) һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турында» 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында күрсәтелгән мәгънәдә кулланыла.

2) 8.5 пунктындагы 3 абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

3) 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- дәүләт яисә муниципаль милекнең бәясе турындагы тәкъдимнәр аукционда катнашучылар тарафыннан сату барышында ачык белдерелә».

4) 8.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сатуда катнашучыны гавами тәкъдим ярдәмендә җиңүчедип тану турында хәбәрнамә сатуга йомгак ясаган көнне гавами тәкъдим ярдәмендә җибәрелә.”;5)

4.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- "федераль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы), Россия Федерациясе субъектлары милкендәге мөлкәтне, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны планлаштыру актлары" сүзләрен "дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планнары (программалары)"сүзләре белән алыштырырга".

6) 4.12 пунктындагы 7 абзацта түбәндәге сүзләрне өстәргә::

- «Әлеге Федераль законның 18 статьясындагы 3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта, аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган зат» сүзләрен өстәргә.

7) 6.3 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт яки муниципаль милекнең бәясе турындагы тәкъдимнәр аукционда катнашучылар тарафыннан сату барышында ачык белдерелә. Сатулар нәтиҗәләре буенча аукционда җиңүче белән килешү төзелә.

8) 6.11, 6.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Аның җиңүчесе» сүзләреннән соң «яисә аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган зат» сүзләрен өстәргә..

9) 6.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- аукционда катнашу өчен дәгъвачы зур күләмдә задатка кертә:

-Дәүләт яки муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 проценты 100 миллион сум һәм аннан да күбрәк тәшкил итә;

-Дәүләт яки муниципаль милекне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 10 проценты 100 миллион сумнан да кимрәк.".

10) 1.6 нчы пунктта. "күчемсез" сүзен алып ташларга.

11) 4.8 нче пункт. түбәндәге эчтәлектәге пунктчалар белән тулыландырырга:

әлеге Федераль законда һәм (яисә) башка федераль законнарда каралган -«мондый мөлкәткә ия булуны гавами сервитут һәм (яисә) чикләүләр белән билгеләү турында белешмәләр;

«конкурс шартлары, аларны үтәү рәвешләре һәм сроклары.».

3. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**